ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
комитетларын төзү турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясындагы 12 пункты һәм 86 статьясындагы беренче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының түбәндәге комитетларын төзергә:

1) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты;

3) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты;

4) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты;

5) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты;

6) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты;

7) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты;

8) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты.

2. Комитетлар әлеге карарга 1 – 8 нче кушымталар нигезендә эшчәнлекләренең төп юнәлешләре буенча закон проектларын эшләүне, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагындагы мәсьәләләрне алдан

карауны һәм әзерләүне, законнарның һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы норматив хокукый актларының үтәлүен һәм башкарылуын тикшереп торуны гамәлгә ашыралар дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 20 сентябре
№ 11-VII ДС

2024 елның 20 сентябрендәге
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты эшчәнлегенең төп юнәлешләре**

1. Конституциячел корылыш нигезләре.
2. Федератив корылыш мәсьәләләре.
3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятен оештыру.
4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарын һәм башка дәүләт органнарын төзү мәсьәләләре, моңа Татарстан Республикасы Дәүләт Советының башка комитетлары карамагындагы мәсьәләләр керми.
5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының, аның органнарының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының статусы.
6. Җирле үзидарә, моңа Татарстан Республикасы Дәүләт Советының башка комитетлары карамагындагы мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү керми.
7. Татарстан Республикасы Конституция советы эшчәнлеге мәсьәләләре.
8. Сайлаулар һәм референдумнар турында законнар.
9. Россия Федерациясе гражданлыгы мәсьәләләре.
10. Татарстан Республикасы дәүләт символлары.
11. Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре һәм мактаулы исемнәре.
12. Дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт.
13. Дәүләт вазыйфаларын һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, дәүләт граждан хезмәткәрләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең социаль һәм пенсия тәэминаты.
14. Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруның гомуми принциплары.
15. Татарстан Республикасының административ-территориаль корылышы.
16. Парламентара хезмәттәшлек.
17. Комитет карамагындагы башка мәсьәләләр.

2024 елның 20 сентябрендәге
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты эшчәнлегенең төп юнәлешләре**

1. Бюджет корылышы.
2. Бюджет процессы.
3. Бюджетара җайга салу.
4. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты һәм аның үтәлеше турында хисап.
5. Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты һәм аның үтәлеше турында хисап.
6. Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлешен тикшереп тору.
7. Салымнар һәм җыемнар турында законнар.
8. Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге мәсьәләләре.
9. Дәүләт һәм муниципаль финанс контроле мәсьәләләре.
10. Бухгалтерлык хисабы һәм бухгалтерлык хисаплылыгы.
11. Кредит оешмалары эшчәнлеге мәсьәләләре.
12. Валютаны җайга салу һәм акча-кредит сәясәте мәсьәләләре.
13. Комитет карамагындагы башка мәсьәләләр.

2024 елның 20 сентябрендәге
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы карарына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты эшчәнлегенең төп юнәлешләре**

1. Татарстан Республикасы икътисадын дәүләт җайга салуы нигезләре, Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү һәм аны стратегик планлаштыру мәсьәләләре.

2. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше фаразы.

3. Татарстан Республикасының инвестиция сәясәте.

4. Татарстан Республикасының сәнәгать сәясәте.

5. Инновацион эшчәнлек өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте.

6. Мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте, Татарстан Республикасы милке белән идарә итү һәм эш итү, хосусыйлаштыру.

7. Интеллектуаль милек, интеллектуаль хокуклар.

8. Эшкуарлык эшчәнлеген, шул исәптән кече һәм урта бизнесны, үстерү.

9. Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге мәсьәләләре.

10. Хуҗалык итү субъектлары эшчәнлегенең гомуми мәсьәләләре.

11. Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендәге мәсьәләләр.

12. Сәүдә эшчәнлеге (азык-төлек мәсьәләләреннән тыш).

13. Бәяләр сәясәте.

14. Кулланучылар хокукларын яклау.

15. Мәгълүмат технологияләре, элемтә.

16. Цифрлаштыру һәм цифрлы трансформация мәсьәләләре.

17. Туристлык эшчәнлеге, реклама.

18. Архив эше мәсьәләләре.

19. Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның гомуми мәсьәләләре.

20. Рәсми статистик хисап.

21. Лицензияләүне оештыруның һәм гамәлгә ашыруның гомуми принциплары.

22. Комитет карамагындагы башка мәсьәләләр.

2024 елның 20 сентябрендәге
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы карарына
4 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты эшчәнлегенең төп юнәлешләре**

1. Торак законнары (торак өлкәсендә социаль ярдәм чараларын бирү мәсьәләләреннән тыш).
2. Төзелеш, шәһәр төзелеше һәм архитектура мәсьәләләре.
3. Территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелеше зоналаштыруы.
4. Территорияләрне төзекләндерү мәсьәләләре.
5. Торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре.
6. Җылылык, электр, газ, су белән тәэмин итү һәм су чыгару мәсьәләләре.
7. Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру.
8. Каты коммуналь калдыклар һәм сыек көнкүреш калдыклары белән эш итү, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча региональ операторлар эшчәнлеге.
9. Транспорт һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү мәсьәләләре.
10. Транспорт мәсьәләләре.
11. Энергетика ресурсларын транспортировкалау.
12. Юл эшчәнлеге, юл хәрәкәтен оештыру.
13. Тарифларны җайга салу мәсьәләләре.
14. Комитет карамагындагы башка мәсьәләләр.

2024 елның 20 сентябрендәге
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы карарына
5 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты эшчәнлегенең төп юнәлешләре**

1. Җир законнары.

2. Табигать ресурслары һәм табигатьтән файдалану, шул исәптән җир асты байлыкларыннан, судан, урманнардан файдалану.

3. Әйләнә-тирә мохитне саклау, шул исәптән җирләрне, су объектларын, җир асты байлыкларын, туфракны, урманнарны, атмосфера һавасын, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын саклау; махсус саклanyлучы табигать территорияләре.

4. Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге (гражданнарның уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре өлешендә).

5. Экологик экспертиза.

6. Аучылык һәм балыкчылык.

7. Җитештерү һәм куллану калдыклары (каты коммуналь калдыклар һәм сыек көнкүреш калдыклары белән эш итүдән тыш).

8. Халыкка экологик белем бирү һәм аны экологик тәрбияләү.

9. Агросәнәгать комплексы.

10. Азык-төлек сәясәте.

11. Коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре.

12. Ветеринария эше.

13. Комитет карамагындагы башка мәсьәләләр.

2024 елның 20 сентябрендәге
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы карарына
6 нчы кушымта

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты эшчәнлегенең төп юнәлешләре**

1. Законлылыкны, хокук тәртибен, җәмәгать иминлеген тәэмин итү, шул исәптән күрсәтелгән өлкәдә гражданнар хокукларын яклау.

2. Коррупциягә каршы көрәшнең гомуми принциплары.

3. Хокук бозуларны профилактикалау һәм җәмәгать тәртибен саклау.

4. Суд органнары һәм хокук саклау органнары кадрлары.

5. Татарстан Республикасында суд системасы, суд бергәлеге органнары, адвокатура, нотариат эшчәнлеге мәсьәләләре.

6. Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге мәсьәләләре.

7. Административ хокук бозулар турында законнар.

8. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе.

9. Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгы, һәлакәттән коткару хезмәтләренең һәм һәлакәттән коткару формированиеләренең эшчәнлеге.

10. Дәүләт яисә хезмәт серен тәшкил итүче мәгълүматны яклау, персональ белешмәләрне яклау.

11. Хәрби хезмәткәрләрнең, суд органнары һәм хокук саклау органнары вазыйфаи затларының социаль һәм пенсия тәэминаты.

12. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты мәсьәләләре.

13. Граждан җәмгыяте институтларының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән хезмәттәшлеген үстерү.

14. Миграция сәясәте.

15. Хокукый культураны формалаштыруга ярдәм итү.

16. Россия Федерациясе хокук системасын үстерү һәм камилләштерү мәсьәләләре.

17. Законнарны системалаштыру мәсьәләләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында чираттагы елга закон проекты эшенең якынча планы проектын төзү.

18. Комитет карамагындагы башка мәсьәләләр.

2024 елның 20 сентябрендәге
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы карарына
7 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының**
**Социаль сәясәт комитеты эшчәнлегенең төп юнәлешләре**

1. Сәламәтлек саклау.

2. Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге (гражданнарның сәламәтлекне саклауга хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре өлешендә).

3. Мәҗбүри медицина иминияте, социаль һәм пенсия иминияте (дәүләт вазыйфаларын һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны, дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм муниципаль хезмәткәрләрне, хәрби хезмәткәрләрне, суд органнары һәм хокук саклау органнары вазыйфаи затларын иминләштерү мәсьәләләреннән тыш).

4. Дару чаралары белән эш итү (ветеринария дару чараларыннан тыш).

5. Физик культура һәм спорт.

6. Хезмәт мөнәсәбәтләре, халыкны эш белән тәэмин итү, хезмәтне саклау.

7. Аерым категория гражданнарын социаль яклау һәм социаль яктан тәэмин итү (гражданнарга торак һәм җир кишәрлекләре һәм (яисә) аларны алуга сертификатлар бирүгә бәйле мәсьәләләрдән, шулай ук дәүләт вазыйфаларын һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны, дәүләт граждан хезмәткәрләрен, муниципаль хезмәткәрләрне, хәрби хезмәткәрләрне, суд органнары һәм хокук саклау органнары вазыйфаи затларын пенсия белән тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләрдән тыш).

8. Гаилә законнары.

9. Бала хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең төп гарантияләре, балигъ булмаганнарга аерым төр товарларны сатуны тыю.

10. Опека һәм попечительлек мәсьәләләре.

11. Граждан хәле актлары.

12. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге мәсьәләләре.

13. Демографик сәясәт һәм яшьләр сәясәте.

14. Патриотик тәрбия бирү.

15. Хәйрия эшчәнлеген һәм ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлеген хокукый җайга салу.

16. Комитет карамагындагы башка мәсьәләләр.

2024 елның 20 сентябрендәге
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы карарына
8 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты эшчәнлегенең төп юнәлешләре**

1. Мәгариф.
2. Мәдәният һәм сәнгать.
3. Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау һәм үстерү.
4. Татар халкының һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче башка халыклар вәкилләренең милли үзенчәлеген саклау һәм үстерү.
5. Китапханә эше мәсьәләләре.
6. Татарстан Республикасының мәдәни мирас объектларын саклау мәсьәләләре.
7. Халык сәнгать һөнәрләрен үстерү.
8. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек.
9. Фән һәм фәнни эшчәнлек.
10. Милли сәясәт һәм милләтара мөнәсәбәтләр.
11. Милли-мәдәни оешмалар һәм дини берләшмәләр.
12. Комитет карамагындагы башка мәсьәләләр.